РАСЛЫЙМ:
Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе, җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру буенча эшче төркем рәисе

________________ Э.Ә. Габдрахманов

« 11 » октябрь 2024 ел

**Җир кишәрлеген файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында Бәяләмә**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре 2024 елның 18 сентябрендәге 31 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Нефтьчеләр урамы буенча урнашкан 40 номерлы шартлы рәвештә рөхсәт ителгән 16:44:010106:2366 кадастр номеры булган җир кишәрлегенә карар проекты буенча рөхсәт бирү хакында гавами тынлауларны билгеләү турындагы карары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең Нигезләмә нигезендә Нефтьчеләр урамы буенча урнашкан 40 номерлы шартлы рәвештә рөхсәт ителгән 16:44:010106:2366 кадастр номеры, 292 кв. м мәйданы булган җир кишәрлегенә - «Иҗтимагый туклану» рекреация билгеләнешендәге зонасында (Р2) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты
(Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының карар проекты) буенча гавами тыңлаулар үткәрелде.

Үткәрү вакыты: 2024 елның 25 сентябреннән 2024 елның 09 октябренә кадәр.

Гавами тыңлауларны оештыручы - җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру буенча эшче төркем.

Гавами тыңлауларны уздыру турында мәгълүмат: Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының мәгълүмат стендында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан ителде.

Җир кишәрлеген файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт сорала

торган җир кишәрлеге белән гомуми чикләре булган җир кишәрлекләренең хокук ияләренә катнаш җир кишәрлекләренә хокукка ия булучыларга 2024 елның 18 сентябреннән 721 номерлы хат җибәрелде.

2024 елның 25 сентябреннән 2024 елның 09 октябренә кадәр Азнакай шәһәре Башкарма комитетында һәм Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлегендә гражданнардан һәм вазыйфаи затлардан язма рәвештә карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул ителде, шулай ук экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу китабында (журналында) да теркәлү алып барылды.

Гавами тыңлауларны уздыру вакыты, урыны һәм формасы: 2024 елның 10 октябрендә мәскәү вакыты буенча 16.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 14 йорт; Азнакай шәһәре Башкарма комитеты. Үткәрү рәвеше - җыелыш, эшче төркем әгъзалары 5 кеше катнашты.

2024 елның 10 октябрендәге карар проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәсе Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлегендә теркәлгән.

Гавами тыңлауларны үткәрү барышында 2024 елның 25 сентябреннән 2024 елның 09 октябренә кадәр шәһәр халкыннан проект буенча җәмәгать фикер алышулары буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр теркәлмәде.

Җыелыш үткәрү барышында 2024 елның 10 октябрендә шәһәр халкыннан карар проекты буенча язма рәвештә тәкъдимнәр һәм искәрмәләр теркәлмәде.

Гавами тыңлаулар материалларын карау нәтиҗәсендә түбәндәгеләр билгеләнде: гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм процедурасы үтәлде һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары таләпләренә туры килә.

**Гавами тыңлауларны уздыру буенча эшче төркем нәтиҗәләре:**

1. Гавами тыңлауларны уткәрелгән дип танырга.
2. «Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең Нефтьчеләр урамы буенча урнашкан 40 номерлы шартлы рәвештә рөхсәт ителгән 16:44:010106:2366 кадастр номеры, 292 кв. м мәйданы булган җир кишәрлегенә - «Иҗтимагый туклану» рекреация билгеләнешендәге зонасында (Р2) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы (Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының карар проекты) буенча карар проектын хупларга.
3. Гавами тыңлаулар материалларын (беркетмәне, бәяләмәне) Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча Комиссиясенә җибәрергә.

4. Җир кишәрлеген файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының мәгълүмат стендында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

Эшче төркем секретаре ______________________ А.З. Авзалова

Эшче төркем эгъзалары

______________________ Л.Ф. Миндубаева

______________________ С.Ф. Шәрәфетдинова

______________________ З.С. Габитова